# ТӘГАЛЛЕМДӘ СӘГАДӘТ
# ЯКИ ГЫЙЛЕМ ҮГРӘНҮДӘ РӘХӘТ ГОМЕР

— Агачларның яфраклары коелып, үләннәрнең чәчәкләре саргаеп, җәй фасылының бетүенә хәсрәтләр чигүдә, кошларның тавышлары үзгәреп, урыннарының бетүенә, гомерләренең тәмам булуына хәсрәтләнеп «әлвидаг-әлвидаг» дия сайрамакта, суларның дулкыннары, агачларның яфраклары бәрелешеп-бәрелешеп куркынычлы тавышлар берлә тавышланмакта, күз алдымда моңлы, кызарган күренеш (манзарә) күңелләремә кайгылар, хәсрәтләр төшерүдә, кояшның батышы, күз алдымны караңгыландырып, кәефсез вакытлар, рәхәтсез хәлләрне яңартуда, Хәлим дә мәктәпкә китә алмавы күңелемдә кайгы өстенә кайгы булып, Хәлимнең дә киләчәк гомерләренең минем шикелле бәхетсез булуларын исәпләтеп, күңелемдәге кайгылар күз яшьләре булып түгелүдә. Алла! Уф Алла! Үзең яраттың галим нәселдән, зур фамилиядән иттең, иптәш кызларымнан аерынкы гыйлем дә бирдең. Бәхетлелегемне уйлаганда Габдерахман кебек бер чи наданга насыйп булдым, улсына да шөкерләр булсын, үземнең бәхетсезлегемне уйламас идем, шуның хакында философ дәрәҗәсенә җитәчәк газиз баламны укытмый калдырам. И Раббем, үзең күңеленә сал да, баламны ничек булса да гыйлем юлына кертеп, дөньямыз- га, ахирәтемезгә файдалы гыйлемнәр насыйп әйлә. Габдерахман! Гыйлем фарыз бит, кыямәт көнне укытмый калдыруыңа ни җавап бирерсең. Баланы надан калдыруда һич файда юк, зинһар җибәриксәнә.

Габдерахман: Баланың күңелен бозып, ниләр сөйләп торасың? Казанда синең балаңнан башка шәкерт юктыр. Яхшы гына бала иде, бозып бетердек, маллар карарга да өйдә булмый, һәрвакыт мәдрәсәдә.

Фатыйма: Алай сөйләмә, Аллага шөкер диң, малайлар берлән ашык уйнап, йомырка уйнап йөрсә, ни эшләр идек.

Габдерахман: Инде намазын укый белде, үзенә кирәкләрен белә, Казанга илтсәң дә безнеке мулла булмас, мулла булырга мулла балалары бетмәгәндер.

Хәлим: Үз кирәгемне белсәм, анда барырга теләмәс идем, гыйлем ул бик тизлек берлә авылларда укып кирәкләрне [белеп] бетереп булмый, мулла булмаган кешегә дә гыйлем фарыз, гыйлемне мулла булыр өчен генә тәхсил итмиләр, белмәгәнне белер өчен, белмәгәннәргә белдерер өчен.

Габдерахман: Синнән күп өйрәнерләр, синең чикле белми торганнардыр.

Фатыйма: Кеше белүе безгә түгел, әнә шул, шуңарга кызыгып укытырга келисең.

Габдерахман: Әлегә чикле укымый торганнар көн күрә алмаганнардыр, сез генә бик беләсез, мине кулсыз калдырып, әллә кая мәдрәсәләргә жулик булырга җибәрергә телисең.

Хәлим: Мәдрәсәгә тел тиермә, атам, мәдрәсә гыйлем казаны, дин сакчысы, динне мөдәррисләр, голямалар саклыйлар, алар барысы да бервакыт шәкерт булган булалар, алар булмаса, безнең надан халыкның зарардан башка бер нәрсәсе юк, аларга тел тиерү дингә тел тиерү була, дингә һәрвакыт шөкранәдә булырга кирәк. Аллага шөкер, мөселман булганмыз, ислам кушканча йөрсәк, дөнья, ахирәт рәхәтләргә ирешермез. Дөньяга килүдән мәгьсуд — дөньяда гына ничек җитте шулай көн уздыру түгел, бәлки дөньяда үземез рәхәт яшәп вә башка мөселман карендәшләремезнең дә рәхәт гомер кичерүләренә тырышып вә гайрәт кылып, ахирәт көнендә әбәди мәсгудиятләр ирешмәктер, болар исә тәхсиле гыйлемнән башка бернәрсә берлә хасил була торган түгел, шуның өчен дә мәдрәсәләргә барып гыйлем өйрәнергә кирәк.

Фатыйма: Инде без дә угылымызны карак булса иде дип изен сорамасмыз. Ул минем кулымнан китә, миңа хезмәт итми дисең, хезмәт итү сука сукалау, урак уру гына түгел, Алла теләсә, мәдрәсәгә барса, зиһенсез бала түгел, шәрикләреннән ким дәрәҗәдә булмас, безнең кавемдә галим кеше бик кадерле вакыт, Алла теләсә, мөгаллим булыр, вазыйфә алыр, безне дә, этиләрем мине гыйлем кеби бер сәгадәткә ирештерделәр, алар мәктәпкә бирмәсаләр, мин әле мужик гавамнан булып, сука сукалар идем дип, шөкранәсеннән безгә дә акча җибәрер.

Хәлим: Иншаллаһ, бер вакыт вазыйфәле мөгаллим булырмын да сезгә дә дип һәрвакыт акча җибәрермен.

Габдерахман: Мин белмим, алай булса, үзеңез теләсәңез ни эшләңез.

Фатыйма: Мин тәңкәләремне рәһен саклауга куеп алыйм.

Габдерахман: Аны кем түләп алыр дип торасың?

Фатыйма: Алла теләсә, үзем түләрмен, бер дә курыкма, сиңа бер эшемезне дә салмамыз.

Хәлим: Әни, алай булса, тизрәк булырга кирәк, сентябрьнең әүвәлге көнендә ул мәктәптә укый башлыйлар, дүрт-биш көн элек анда булыйк.

Фатыйма: Мин Әсма абыстайга барыйм әле, Кәрим абзыйга сөйләсен, Алла теләсә, бирерләр, алар гыйлемнең кадерен белә торган кешеләр.

Хәлим: Анам, бу кадәр бәни мәктәпкә бирмәгә тырыштың, бусында гына зинһар кимчелек (косур) кылмаңыз.

Фатыйма: Алла теләсә, бирерләр, балам.

Хәлим: Әй, Алла кушып, бирсәләр иде, үзләре дә никадәр саваплы булырлар иде.

Фатыйма ханым Әсма абыстайларга барыр.

Әсма абыстай каршы алып: Сәламәтме, Фатыйма?

Фатыйма: Әлхәмделиллаһ, бик сәламәт.

Әсма: Балаларыгыз сәламәтләрме? Хәлимне мәдрәсәгә җибәрмисезме әле? Кәрим абзыең, бүген мәчеттә Хәлим Коръән укыды, бигрәк яхшы укый икән, атасының тиреслеге берлә укымый калмаса ярар иде, дип кайткан иде. Ничек булса да инде, күз чыгарып, баш ярып булса да мәдрәсәгә илтергә карагыз инде, Фатыйма.

Фатыйма (исәпләп торып): И Әсма абыстай, бик җибәрергә телим дә, үзенең дә бик барасы килә, атасы шул бер дә риза булмыйча йөртте, инде ризаланган төсле булса да, бер дә акча бирми, әле шул, Әсма абыстай, Хәлим елый-елый: «Әни, зинһар барып Кәрим абзыйлардан әзрәк акча сора»,—дигәч, ояла-ояла гына сезгә шуның өчен килгән идем.

Әсма: Аның ни ояты бар, Фатыйма, бер дә оялма, Алла теләсә, Кәрим

абзыең бирер. Син ашарга-эчәргә сорамыйсың, балаңа фарыз булган гыйлемне үгрәтергә келисең.

Фатыйма: Инде бирсә, бигрәк яхшы булыр иде, Хәлим дә сикерә-сикерә дога кылыр иде.

Әсма: Алла теләсә, бирер. Кая илтергә келисең?

Фатыйма: Алла насыйп итсә, Казанга илтергә келим инде!

Әсма: Фатыйма, илтүе илтү, инде яхшырак мәдрәсәгә кертергә тырыш. Бу елда наданлыкның кадере бетеп бара, Казанда бөтен мәдрәсә яхшы түгелдер. Әнә, былтыр сөйләгәннәр иделәр, Габдерәүф хәзрәтнең урынына угылын мәхдүм итеп куйганнар икән дә, ул бик надан булып, бер дә мәдрәсәгә кермәгәч, йөздән артык шәкертләр бер елда таралып беткән.

Фатыйма: Шулай инде ул безнең халык, гыйлемгә карамый, нәселенә карый. Шунда бәгъзе кешеләр Әхмәт әфәндене мөдәррис итәргә келәгәннәр, Әхмәт әфәнде, беләсең инде, җаны бөтен дөньяга киткән уннан артык китап чыгарган инде, үзе тәүфыйклы, үзе дәрескә бик тырыш, бик яшь вакыты, нидән дәрес итәргә келәсә – булдыра. Шул кешене куймыйча, мәхдүмнәрен куйганнар, ичмасам тәүфыйклы да түгел, ди.

Әсма: Соң, Фатыйма, сез Хәлимне кайсы мәдрәсәгә куярга келисез?

Фатыйма: Белмим инде, Әсма абыстай, үзем шул яңа мәктәпкә бирергә келим дә, Хәлим үзе дә былтыр калага барганда кереп карап торган, шәкертләрнең күп белүләренә, мөгаллимнәрнең яхшы укыту, яхшы тәрбия кылуларыма исе китеп әле дә сөйли әле, шуның өчен мин шунда барсам иде, ди.

Әсма: Ул нинди мәдрәсә соң, мин аны бер дә ишеткәнем юк?

Фатыйма: Ул мәдрәсәнең исеме «Дарелтәдрис», мөдәррисе Казанның Гали әфәнде, бик галим кеше, гарәпчә әллә никадәр китаплары бар, ике мөгаллим, икесе дә Гали әфәнденең үз шәкертләре, аларны да бик мактыйлар, имтиханда бөтен кешеләр тәбрик иткәннәр, Кәрим абзый аны, гәзитәдә күргәндер, бик мактап язганнар дигән иде. Инде, Әсма абыстай, аның мөдәррисе Гали әфәнде булгач, мөгаллимнәре дә үз шәкертләре булгач, ул

мәдрәсә яхшы булмый ни булсын инде, анда сөйләргә ни калды, бөтен Казан йортында аның кебек мәдрәсә юк.

Әсма: Алай булса, Фатыйма, ничек булса да шул мәдрәсәгә илтергә тырыш инде. Расхут ничек икән?

Фатыйма: Расхут авыррак шул, һәр елга алтмыш тәңкә түләп керергә.

Әсма: Киеменә дә, китабына да кирәк шул.

Фатыйма: Улсы инде, Әсма абыстай, җыенысы, шул, акчадан бер алтмыш тәнкә булса, бу ел өчен була инде.

Шул арада Кәрим абзый килеп керер.

Әсма: Син, монда кеше бар иде.

Кәрим: Ул кем соң?

Әсма: Фатыйма.

Кәрим: Алай икән, бик яхшы, кунак ит, без элгәре кечкенә чакта мәрхүмә аның әнкәсе Мәркәй абыстайдан укыган идек, балалары сәламәтләр, диме? Хәлим ни эшләп тора, ди? Мәктәпкә җибәрәләрме?

Әсма: Җибәрергә келиләр, Фатыйма шуның өчен киңәш итәргә килгән.

Кәрим: Бик яхшы, Алла хәерле итсен. Кайсы мәктәпкә?

Әсма: Әйтә дә белмим, «Дарелтәдрис» атлы диме? Казанда, яңа мәдрәсә.

Кәрим: Ә! Бик яхшы булыр, безнең Казанда аның кебек мәдрәсә юк, бик кирәкле гыйлемнәр, тиешле фәннәр генә укыталар, ул иске мәдрәсәләр төсле, берсенең сүзен берсе ишетмичә һай-һуй кычкырып ятмыйлар, ни укыдылар, шуннан имтихан бирәләр. Соң Габдерахман риза була микән?

Әсма: Риза була да, бер дә акча бирмидер ди шул, шуның өчен әле Фатыйма да бераз акча тыңлап тормассызмы дип килгән.

Кәрим: Үзләренең күпме акчалары бар икән?

Әсма: Әле бер дә акчалары юктыр ахыры.

Кәрим: Анда, Фатыйма, һәр ел алтмыш тәнкә биреп керергә кирәк, сигез ел укытсаң, бик күп кирәк шул.

Фатыйма: Ул инде бу елга булса ярар иде әле, икенче еллары бушлай тора алмасмы, үткенрәк, тиешлерәк шәкертне ун кешегә бер кеше бушлый

алалар икән, безнең Хәлим дә сабакка җитеш кенә, Алла теләсә, тырыш та булыр, шулай итеп, бүтән елларны алмаслармы дип торамыз.

Кәрим: Мин илле тәнкә акча бирәм, ун тәнкә ничек булса да Габдерахман бирсен, үз баласы  ласак, ник ул бер дә карарга теләми, мин әле өйлә намазыннан чыккач орышышмакчы булып кергән идем дә, өйдә юк, диделәр.

Әсма: Мин алай бурычка бирмим, зәкятымыздан булыр, Хәлимне мин бик якын күрәм, бөтенләй дә укытыр идем, алай ук байлыгым юк.

Фатыйма күзләреннән шатлык яшьләре чыгарып: Аллаһе Тәгалә рәхмәт итсен, дөнья-ахирәттә шатлыклы гомерләр насыйп әйләсен, шундый сабый баланы укытырга теләвеңез өчен Аллаһе Тәгалә оҗмах сарайлары насыйп әйләсен!

Кәрим: Амин! Ул һәркемгә шулай кирәк тә, безнең халыкта бер дә шәфкать юк шул, шундый яхшы укый торган балаларны укыта алмыйча әрәм итеп калдыралар, ахыры, гыйлем фарыз, ата-анасының көче җитмәсә, кардәш-кабиләсе укытырга тырышырга кирәк.

Кәрим: Мин чыгам, яхшылап утырыгыз, алай булса да Хәлим мине күрмичә китмәсен әле.

Фатыйма: Ярар, Аллаһ теләсә, күрер, ул инде сезне атасыннан артык күрер.

Әсма: Фатыйма, инде соң кайчан китәсез?

Фатыйма: Инде, Әсма абыстай, Аллага шөкер, акча булды, ун тәнкәсен генә тәнкәләремне заклат салып та алырмын да тизрәк илтергә кирәк.

Әсма: Ай, алай ярыймы соң, тәнкәләреңне салма, ун тәнкә генә үзем бирәм, изгелек тизлек берлә ди түгелме соң?

Фатыйма: Әйе, «Иннәма әлихсану биттәмам»ның мәгънәсе шул-шул инде, бик, Алла разый булсын, Әсма абыстай. Хуш, Әсма абыстай.

Әсма: Хуш, Фатыйма, хуш.

Фатыйма өйгә кайтып керер.

Хәлим: Әни, ни булды, бирделәрме?

Фатыйма: Аллага шөкер, исәпләгәнчә генә булмады.

Хәлим: Әй әнием, газизем! Әллә күп бирделәрме? Зинһар тизрәк сөйлә, шатлыгымнан мием шашу дәрәҗәсенә җиткән.

Фатыйма: Угылым, Аллага шөкер, Кәрим абзый илле тәнкә, Әсма абыстай ун тәнкә бирде. Бу елга бөтенләй түләп керергә җитә.

Хәлим: Әй Раббем, сиңа нә дәрәҗә шөкерләр кылырга белмим, синең миңа ярдәмеңә каршы шөкерләр бәнем кодрәттән килмәдекене белерсең, гобудияттән башка сиңа нә кылыйм, бән колың. Әле эстәсәң — бирерсең, теләсәң—алырсың, бирсәң—тәшәккердә булырым, алсаң—сабыр кылырмын. Әй Раббем, бу көнне шатлыктан яраттыңмы әллә? Бак, шул төрле кояшның (зыясы) яктылыгы гүя минем өчен холыйк иделмеш (гарб җәнүби) кышкы кояш баешыннан искән җилләр Хәлимгә «сәгадәт, тәгаллем — сәгадәт» дигән сүзләрне сөйлиләр. Җәй фасылының үстердеге яшел үләннәр, төрле сачәкләр, хуш-хуш исләр һәр каюсы миңа көлеп: «Хәлим, сине тәбрик идәрез»,— диерләр. Минем шул шатлыклы көнемдә галәме әрзәк халкы музыкачылары музыкалар уйнарлар, сандугачның, садасыннан: «Мәктәп юлы — җәннәт юлы», карлугачның тавышыннан: «Вар мәктәбә, ал мәртәбә», кенарикның тәрмененнән: «Ит тәгаллем, күр тәкәрем»,—дигән сүзләр берлә минем шул мәктәпкә китүемне тәбрик итәрләр. Әй Раббем, шул Кәрим абзый илә Әсма абыстайларны рәхмәтеңнән яраттыңмы, минем кеби гариб, фәкыйрь бер шәкерткә ни кадәрле (иганә) ярдәм кылдылар. Йа Раббем, аларга ничек дога кылыйм, үзең, Раббем, күңелемне ничек шатландырганнарын беләсең. Әни, ни эшлим, шатлыгым тамагыма сыймый. Әбиләргә, бабайларга Коръән укып килим, Кәрим абзыйларның да нәсел вә нәсәпләренә багышлармын, Аллага шөкранә кирәк.

Хәлим, тәһарәт алып, зиярәткә китәр. Фикереннән ниләр кичә? Хәлим (эченнән исәпли): Аллага шөкер, акча да булды, әти дә рөхсәт бирде, Казанга баргач, мәктәпкә кабул итәрләр, бу ел, Алла теләсә, әүвәлге сыйныф шәкерте булып, әүвәлге сыйныфларның киемнәрен киярмен, мәктәптә кавагыйде гарәбидән истифтах укыймын, аңардан имтихан бирермен дә истикмаль берлә

дәрүсе шифаһия укыймын, гарәби гыйбарәтләр тәртип кылырга өйрәнеп, гарәпчә сөйләшергә өйрәнермен, аннан башка да тарихы ислам укырмын, искедәге бабайларның дин юлында, милләт юлында ижтиһадларыннан гайрәт алырмын, җәгърафия укырмын, үземезнең тора торган җирнең кайсы төш икәнен белермен, мәмләкәтләр нинди икәнлеген белермен, иманы ислам өйрәнермен, яшь булсам да дин эшләрен яхшы белеп, дөньядан да хәбәрле булып, иманымны, игътикадымны гүзәлләрмен, аннан ары, Алла теләсә, җәй көне имтихан биреп, мәктәптән чыгармын, имтихан мәҗлесендә бөтен кешене белүемә гаҗәпкә калдырырмын, икенче елда акчасыз кабул итәрләр, мәктәптән чыккач, бәдәлсез тәхсил итәрмен, унсигез яшемдә мәктәпне тәкәммел итеп бетереп, икенче бер мәктәпкә кереп, һөнәр өйрәнермен, бу шәһадәтнамәм илә "Дарелтәдрис" кебек бер мәктәпкә мөгаллим булырмын, бер тарафта  мәктәп тәрбия кылып, икенче тарафтан китаплар, рисаләләр тәртип илә кавемемә хезмәт итәрмен. Хезмәтем хакында кардәшләрне рәхмәт укытырмын, сигез сәнә тәхсил итсәм, лөгате гарәбкә, лөгате фарсига тел чыгарып, рус теленә мәһарәт әшналык кәсеп итәрмен, теләгән телдәге китапларны укып, кирәкләрен тәрҗемә кылып, рәхәт-рәхәт гомер кичерермен.

Зиярәткә барып, Коръән укып, шатланып кайтырга башлар. Кайткан вакытта исәпләп әйтә: И мескен кабер әһелләре, минем Коръән укуыма рәхәтләнеп, миңа никадәр дога кылдылар икән! Минем гыйлем юлына кереп мәктәпкә баруыма, Кәрим абзыйларның мине җибәрүләренә бәйрәм ясап, газаплыларның газаплары күтәрелеп, рәхәтлеләренә нинди дәрәҗәләр арттырылган икән, тизрәк өйгә кайтыйм да әшьялар-әйберләремне хәзерләрмен. Тизрәк парахутка барып җитәргә кирәк.

Кайтып: Әни, әйберләр хәзерләдеңме? *Алла теләсә*, иртәгә китәрмен.

Фатыйма: Угылым, һәркайсы хәзер, иртәгә җомга укып чыгармыз, юлга тәһарәт өчен комган алыйкмы икән?

Хәлим: Әни, комган урынына шешә генә *алыйк* анда тәһарәт алырга крант та була, истинҗага *шешә дә* яхшыдыр.

Фатыйма, көлеп: Ярар, угылым.— Эченнән генә*:* Әлхәмделиллаһ, нинди

дәкыйк, нечкә, ниндәен сүзләр сөйли, әлбәттә, бервакыт бөек хәким улачак.

Габдерахман килеп керер.

Фатыйма: Әтисе, Аллага шөкер, Кәрим абзыйлар акча бирделәр, без иртәгә китәрмез дип исәпләп торамыз.

**Габдерахман:** Ярый инде, Алла хәерле итсен, әле **мине дә Кәрим** абзый чәйгә чакырып, шуны сөйләп утырды. Мин дә инде ун сум бирем, инде, Фатыйма, үзең беләсең, әллә ни байлыгыбыз юк, бүтән чакта да шулай аз-аз булса да җибәрермез, иртәгә үзем пристаньга ат җигеп илтермен.

Фатыйма: Мин, парахутка бераз бавырсак пешерик, дим.

Габдерахман: Улсын үзеңез беләсез.

Хәлим шатланып Кәрим берлә күрешеп килер. Иртәсе көн җомгада Хәлим Коръән укыр, бөтен халык яхшы укуына исләре китеп торырлар, дога кылгачтан, Кәрим абзый аякка калкып: «Җәмәгать, Хәлимне Казанга мәктәпкә җибәрергә телимез, фатихада булыгыз». «Хәзрәт, ягез, бер фатиха»,— дип, бөтен мәчет халкы Хәлимгә дога кылырлар. Хәлим дә хәзрәт берлә, соңра мәчет картлары берлә күрешеп чыгып китәр.

Габдерахман да өйгә кайтып, ат җигеп, китәрләр.

Хәлим: Әлхәмделиллаһ, безгә дә Аллаһе Тәгалә бу эшләрне (мөяссәр әйләде) күрергә язды.

Фатыйма: Аллаһе Тәгалә тәүфыйк, бәхет биреп, дөнья вә ахирәт, шатлыклы гомерләр насыйп әйләсен.

Пристаньга барып җитәрләр.

Габдерахман: Угылым, хуш. Хуш — саг улыгыз! Фатыйма, тизрәк кайтырга тырыш инде.

Хәлим: Әти, хуш бул инде, фатихада булыгыз, хәзрәтләрдән дә фатиха үтен.

Габдерахман: Хуш,бәбкәм, хуш.

Габдерахман да китәр. Тиз парахут та килер.

Хәлим кантурга кереп: Третий класста комната бармы?

Конторщик: Юк.

Хәлим: Хатыннарга махсус дамский комнат бармы?

Конторщик: Бар.

Хәлим: Билет бир.

Конторщик: Кая кадәр?

Хәлим: Казанга.

Конторщик: Ике билет — бер сум илле тиен.

Хәлим: Мә акча!

Конторщик: Билетларыңызны ал.

Хәлим: Ничә сәгать барыр?

Конторщик: Сигез сәгать.

Хәлим: Хуш.

Конторщик: Хуш!

Хәлим: Әни, сигез сәгатьтә барып җитәрмез.

Фатыйма: Угылым, миңа бик уңайсыз булмасмы икән? Кешеләр бик күп булыр.

Хәлим: Дамский бүлмәгә керерсең, бар, диде.

Фатыйма: И, бик яхшы икән, Аллага шөкер.

Парахут килер, Хәлим анасын дамскийга кертеп, Казанга китәрләр. Хәлим дә гомуми бүлмәгә кереп китәр.

Казанга барып җитәрләр.

Фагыйма: Хәлим, безнең монда Рәхимә абыстайлар бар, аларга төшәрмез, ямщик ялла!

Хәлим: Алар кайсы урамда торалар?

Фатыйма: Тихинский урамда.

Хәлим ямщик барып яллар, Казанга менеп җитәрләр. Рәхимә абыстайларга барып керерләр.

Рәхимә абыстай каршы алып, бик кадерләп: Хәлимне әле мәдрәсәгә китердеңезме?

Фатыйма: Әйе, Рәхимә абыстай.

Рәхимә: Кайсы мәдрәсәгә куймакчы буласыз?

Фатыйма: Яңа мәдрәсәгә.

Рәхимә: Бик яхшы булыр, ул мәдрәсәдә өч-дүрт көннән укый башларлар инде.

Хәлим: Шәкертләр килдеме икән?

Рәхимә: Килгәндер инде, аларның теләгәне килеп, теләгәне, китеп йөрми, вакытлы гына киләләр, вакытлы гына китәләр.

Фатыйма: Инде без ни эшләрмез икән, сорашып белешергә кирәк иде?

Рәхимә: Әүвәл Фатих әфәнденең өенә барып хатынына сөйлик тә, Әсма ханым безгә бер сүз әйтеп җибәрер.

Фатыйма: Бик яхшы, өйдә булса ярар иде.

Рәхимә: Хәзер алар өйдә булырлар.

Фатыйма: Алай булса, Рәхимә абыстай, без барып күрешик әле.

Рәхимә: Әйдә, барыйк соң, Фатыйма.

Фатыйма берлә Рәхимә Фатих әфәнделәргә китәрләр. Барып кергәч: Әсма ханым, сәламәтме сез?

Әсма: Әлхәмделиллаһ.

Рәхимә: Бик сәламәт торасызмы, мөгаллим өйдәме?

Әсма: Өйдә иде, әле мәктәпкә киткән. Бу арада анын эше бик күп, хәзер мәктәпнең ачылыр вакыты җиткән. Иртәгә монда алу имтиханнары була, беренче сентябрьдә дәрес башлана.

Рәхимә: Безнең йомышымыз да шул иде, менә бу минем сеңелем, угылын алып килгән, мәктәпкә бирмәкче була, шуны алырлар микән? Без кемне күреп сөйләшик икән, шуны сездән белергә килгән идек.

Әсма: Бик яхшы иткән, бик рәхмәт, баласын укытырга китергән өчен Аллаһе Тәгалә дөнья, ахирәт әҗерләре бирсен.

Рәхимә: Соң, Әсма ханым, без ничек белешик икән?

Әсма: (гариза) үтенечнамә язып сорагыз, кабул итсәләр, имтиханга чакыртырлар, чәһаршәнбе көн имтиханнары булачак.

Фатыйма, кайтып,Хәлимгә язарга кушар, Хәлим язып мәктәп мөдире Хәйретдин байга бирерләр, чәһаршәнбе көн имтихан мәҗлесенә

Хәлимне чакырып, имтихан кылырлар. Хәлим дә имтиханда бик үткен чыкмаса да: «Зиһенсез бала түгел, Аллаһе теләсә, булдырыр»,— дип, кабул итәрләр, Хәлим шатлана-шатлана мәктәпкә килер. Кече атна (пәнҗешәнбе) көн мәктәпкә җәмгъ шәкертләрне кабул итеп, язып, мәктәп киемнәрене кидererләр, Хәлим дә әнкәсенә киемнәрен илтеп биреп, мәктәп киемендә калыр.

Фатыйма, кайтмакчы булып, Рәхимә абыстайга әйтә: Абыстай, инде Аллага шөкер, Хәлимне кабул кылдылар, эшләремез үземез теләгәнчә булды, мин, Алла насыйп итсә, кайтыйм инде, Хәлимне күрим дә, күрешеп китәрмен.

Рәхимә: Бүген җомга көн инде, Фатыйма, бүген китмә, бөтен шәкертләр җомгага безнең урамнан узалар, карап калырмыз, безгә аларны карар өчен бай хатын-кызлары да киләләр.

Фатыйма: Безнең Хәлим дә килер микән?

Рәхимә: Берсе дә калмый, аларга җомгадан калу түгел, бөтен намаздан да калырга ярамый.

Фатыйма: Һәрвакыт шулай биш вакыт намазга киләләрме?

Рәхимә: Юк, аларның монда үзләренең мәчетләре бар, шунда бармый калырга ярамый.

Фәхрия: Әнкәй, киләләр.

Рәхимә: Фатыйма, тиз бул,— дип, тәрәзәдән карый башларлар.

Фатыйма: Карасана, Рәхимә абыстай, ниндәен әдәпле баралар, берсенә берсе дә карамый, безнең Хәлим дә шулай әдәпле булыр микән?

Рәхимә: Ай, булмыймы соң?

Фатыйма: Ул бала чакта өйрәтергә була. Менә боларны шулай әдәпле булырга өйрәткәннәр.

Рәхимә: Менә монда Сәгъди хәзрәт шәкертләре бар. Алар да шул мәчеткә баралар, күрерсең, әллә ни кылынып бетәләр, берсе берсе берлә көлешкән булып, ялтыр-йолтыр күзләрен тәрәзәгә әйләндерәләр, әйтерсең, аларны монда көтеп торалар. Ул, шәкерт булгач та, бары да әдәпле булмый, әдәп өйрәтсәләр генә әдәпле була.

Фатыйма: Ай Рәхимә абыстай, мин боларга исем китте, ничек бу чикле өйрәткәннәр, болар нинди кеше булырлар икән?

Рәхимә: Сөйләмә инде, Фатыйма, Хәлим бигрәк мәхәббәтле икән, үзенә дә әйт инде, бик тырышсын.

Фатыйма: Җомгадан соң монда керсә ярар иде, күреп калыр идем.

Рәхимә: Әйткән идең, керер.

Хәлим дә килеп керер.

Фатыйма: И угылым, мәчеткә бигрәк килешле барасың икән.

Хәлим: Әни, Аллага шөкер инде, сөйләмә, ул мәдрәсәсе матурлыгы, мин төшемдә дә андый матур өй күргәнем юк иде.

Фатыйма: Угылым, бәхетең бар икән, әй кадерен бел инде, бик тырыш, шәрикләреңнән бер дә артка калырга келәмә. Беләсең, Кәрим абзыйлар да укырга дип акча бирделәр, укымый торсаң, сиңа да бик оят булыр, безгә уңайсыз булыр, ничек булса да тырыш, алга чыгарга кара, укымаганнары да булыр, аларга карап: «Болар укымый, мин дә әле укымыйм»,—димә, укыганнарына кара, имтиханда менә күрерсең, кайсылары кадерле булыр.

Хәлим баш салып тыңлап тора: Әни, үзем дә беләм инде, Алла теләсә, бик укырмын, бер дә курыкмаңыз.

Рәхимә: Хәлим, уку белән генә дә эш булмый, укыганны тотарга да кирәк, бик яхшы булырга тырыш, бик тәүфыйклы, бик әдәпле, бик гакыллы бул.

Хәлим: Алла теләсә, сез әйткәнчә йөрермен, бик яхшы әйтәсез. Әни, соң кайчан китәсең?

Фатыйма: Угылым, бүген китәм дигән идем.

Хәлим: Әтигә дә инде яхшырак итеп, кызыгырлыграк итеп сөйлә.

Фатыйма: Ярар, Алла теләсә.

Хәлим: Әни, әтидән дә дога үтен, безнең өчен һәрвакыт хәер-догада булыгыз.

Фатыйма (күзләреннән яшьләр чыгарып): Булмыйбызмы соң инде, үзең дә әти-әнигә, бөтен өй җәмәгатемезгә тигез гомер бирсен дип телә инде. Без

хәзер китәмез инде.

Хәлим: Әни, хуш булыгыз инде, этигә, дога үтенеп, сәлам диегез.

Фатыйма: Хуш, Хәлим.

Хәлим мәктәпкә китәр. Фатыйма да өенә кайтыр.

Җомга көн беренче сентябрь җомгадан соң мөгаллимнәр килеп Коръәннән кыйраәт башларлар, шәкертләргә иртәгә гомуми дәрес башланачагын сөйләрләр. Хәлим мәктәпкә керүенә һәрвакыт шөкранәдә булып, шәрикләреннән алга чыгарга тырышып, бик укыр, урынлашып җиткәч, сабаклары җайлангач, Хәлим өенә хат яза: «Газизләрем! Әлхәмделиллаһ, хәер-догаларыңыз хакынада бик саг, бик сәламәт гомеремне, дәресләремне укып рәхәт-рәхәт шатлыклы **эшләр** берлә уздырам, Аллаһе Тәгалә рәхмәте берлә, сезнең хәер-фатихагыз хакында көннән көн дәрәҗәм арта бара (шәһри) айлык имтиханымызда өченче дәрәҗәдә булган идем, Аллаһе Тәгаләгә мең-мең мәртәбә шөкерләр булсын, (рамазан) имтиханымызда беренче улдым, бөтен мөгаллимнәр бәңа рәхмәт күзләре берлә карыйлар, (сәнәви) еллык имтиханымызда беренче булып чыксам, икенче елга акчасыз алырлар, һәрвакыт безне фатихадан онытмагыз! Хәлим. Вәссәлам.»

Хәлим һәрвакыт дәресне тырышып укып, еллык имтиханында да беренче булып шәһадәтнамә алып, аерынлыклы яхшылык язуы алып мәктәптән чыгар. Икенче ел акчасыз тәхсил итәр, ул елны беренче булып, елга кадәр беренче булып килер. Май числосының 27 нче көннәрендә Хәлим актыккы ел имтиханын алуы беренче булыр. Сигез ел беренче булганга, шәһадәтнамәгә башка, имтихан бүлегенә бер Коръән Газыйм берлән бер сәгать бирерләр.

Хәлим, мәктәпнең бакчасында үзеннән үзенең элгәреге хәлләре берлә үлчәп әйтә: «Мин кечкенә бер малай идем. Малайлар арасында уйнап йөри идем, алай булса да авылымызда мәдрәсә ачылгач та барып сабак укый идем. Мәктәптә сабагымны белгәнгә, мулла абзый да ярата иде, этигә һәрвакыт мине зуррак мәдрәсәгә илтергә куша иде. Әти дә, үзенең байлыгы булса да,

расхут күп булыр дип, мине мәдрәсәгә илтүдән курка иде. Аллаһе Тәгалә рәхмәте, минем бәхетем, Аллаһе Тәгалә Кәрим абзыйларның күңеленә рәхмәт салды, мине җибәрергә акча биреп, әтине дә игә китерделәр, мәдрәсәгә дә килдем, бигрәк бәхетлелектән (Дарелтәдрис) мәктәбенә кабул иттеләр. Бер сала малае булып килеп, һәр ел беренче булып имтихан кылынып, сигезенче ел мине бөтен халык алдында үземне мактап мөгаллим әфәнде сүз (нотык) сөйләп, бөтен халыктан тәбрик иттерде. Мөкяфәтемез дә (имтихан бүләге) Кәляме кадим берлә бер көмеш сәгать бирелде. И Раббем, рәхмәтеңә бик шөкранә идәрем. Мин соң авыл урамында йөргән малай түгелме, хәзер дә кайда йөрим, Казанның беренче мәктәпнең бакчасында йөрим. Дөнья оҗмахы кебек бакчада яшь-яшь үләннәрдән, хуш-хуш исләрдән, матур-матур агачлардан, миңа карап көлемсерәп торган кояштан, рәхәтләндерер өчен искән җилләрдән, энҗе кебек гөлләрдән, гаҗәп – гаҗәп кошлардан: Хәлим, әүвәл кем идең, хәзер кем булдың? Үз телеңне белми торган малай идең, хәзердә гарәп телен, фарсы телен, төрек телен, рус теленнән белемле кеше булдың. Элгәре фөнүн ни икәнен белми идең, хәзердә фөнүнне үзең ясаган кебек белдең, моны бик бел, Аллаһе Тәгалә сиңа фазылыннан бирде, син үз кардәшләреңә ригая кылып, аларның надан калуларын теләмичә, укытып белдерер өчен иҗтиһадта бул, Аллаһе Тәгалә сиңа бу кадәр гыйлем берлә фөнүнне үзең өчен бирде дип белмә, безнең кавемемез өчен минем миемне (димагымны) тутырды, кирәгенчә генә мин аларга бушатырмын дип, син үзеңнең кавемең наданлыгына карап, икенче кавемнәрнең гыйлемнәренә гыйбрәтләр алып, алар шикелле итәргә тelә», —дип сөйлиләр. Өйгә дә хат языйм, алар да бер шатлансыннар, мескен әни минем сәгадәтемә никадәр тырышты, аның хезмәтләрен кайтарып бетерүдән гаҗизмен, Кәрим абзыйлар, минем баш сәгадәтемә алар сәбәп булды. Алар акча бирмәсәләр, мин ничек килер идем дә ничек тәхсил итәр идем, аларга да бер хат языйм»,—дип, Кәрим абзыйга хат язар: «Сәгадәткә ирештерүчем, әлхәмделиллаһ, мәктәпне тәкмил кылып, имтихан кылындым, имтиханда беренче булдым. Хакымда мөгаллим әфәнде бөтен халык алдында нотык сөйләде, бөтен мәҗлес кычкырып тәбрик иттеләр,

мөкяфәтемә бер сәгать илә Коръән Газыйм  алдым, бөтен гомум хәзер анама, бабама, мәктәпкә китерүгә тәргыйб кылучыларга, тәрбия кылучыга дип фатиха кылдылар, сезнең тәрбия хакында ни дәрәҗәгә васыйл булдыгымны вә сезгә ничек хезмәт итәргә кирәклекне бик беләм. Ул хезмәттән гаҗиз улдыгымны вәсилә итеп, гафуларыңызны үтенәмез, Аллаһе Тәгалә безне тәрбияңезгә мең-мең рәхмәтләр күндерсен. Хәлим. Вәссәлам».

Хәлим өенә дә хат язар. Каршы хат килер.

«Газиз балам! Казан мәктәбенең беренче шәкерте безнең баламыз дип гәзитәгә язылудан ни дәрәҗә шатланганымызны тел берлә сөйләүдән гаҗизмен. Шул көнне Аллаһе Тәгалә безгә шатлык өчен генә яраткан дип белдек. Әлхәмделиллаһ, беренче булгансыз, беренчелегеңне югалтма. Икенче елга һөнәр мәктәбенә керәм дигәнсез, Аллаһе Тәгалә хәерле кылсын, үзеңнең шул дәрәҗәгә җитешүеңә Аллаһе Тәгаләгә һәрвакыт хәмедләр әйтеп, каумият эшләреңнән, шул наданлык караңгылыгыннан коткарырга тырыш. Вәссәлам. Фатыйма.»

Хәлимгә Казанга икенче бер мәктәпкә мөгаллим булырга урын (тәгайен) билгеләгәннәр. Икенче елны унтугыз яшендә бер мөгаллим булып, дәхи сәнаигы нәфисә мәктәбендә бер шәкерт булып, мәктәптә үзенә билгеләнгән бер өйдә тора башлады. Дөньяда рәхәт торырлык вазыйфә булганга, үзе дә яхшы галим, тәүфыйклы мөгаллим булганга, һәрвакыт кимчелек кылмаенча торганга, Аллаһе Тәгаләгә шөкранә кылып, ата-анасына, Кәрим абзыйларга догада була иде.

Хәлимнең бер җитмәгән нәрсәсе булса, ул да хатыны юклыгы иде. Дәхи хатыны берлә ничек торасы иде, шуның өчен һәрвакыт исәпләп, дөньяда ничек торырга дип төрле эшләр төшенә иде. Хәлимнең һәр эшеннән бер гыйбрәт алып, Хәлимгә бик мәхәббәт кылган Рәшит бай Хәлимгә кызын бирү хосусында мең төрле уйлар уйлап, чамасыз хәйләләр төзәр иде. Хәлим бервакыт Рәшит байга шул тугрыдан сүз ачып, Рәшит абзый, форсаты ганимәт белеп, эченнән генә «Алла теләсә, эләктерәмез»,— (дип): «Мин, Хәлим, үзем дә шул эшне исәпләп тора идем, син белми торгансың да, мин сине бик якын

күрәм, яраса, үземә угыл итәр идем».

Хәлим: Соң, Рәшит абзый, минем монда сездән башка кешем юк инде, миңа бу турыда бер гакыл бирегез.

Рәшит тә башын кашып: Исәпләшеп карыйк, син нинди кыз алырга келисең, без яраткан әллә сиңа ярар, әллә юк.

Хәлим: Мин аны ничек әйтим инде, нинди булсын, диим.

Рәшит: Монда бер кыз бар, әллә бирерләр. Ләкин ата-анасы зурраграк кешеләр. Бирсәләр, безнең белүгә, бик яхшы булыр төсле. Кызның төсен, йөрешен, укымышын бик мактыйлар, эшкә дә оста диләр.

Хәлим: Холкы ничек икән, мин бигрәк холкына карарга келим.

Рәшит: Ул кызда барысы да килгән, диләр. Инде кызга кызыгып зурраграк кешеләр дә сораганнар.

Хәлим: Ул соң кем кызы инде?

Рәшит: Аны кем диим, ул син белә торган кешең түгел тукта әле, кайтып җәмәгатькә сөйләп карыйм, минем мактау белән генә эш бетми, хатын-кыз эшен алар яхшырак белүчән,—дип, китеп барыр.

Кайтып: Хатын, монда кил әле!

Гайшә абыстай: Бүген намазда озаграк тордың, карт.

Рәшит: Хәлим берлә сөйләп тордым, өйләнергә кели.

Гайшә: Кемне алмакчы була?

Рәшит: Алай текәлгән кешесе юк, миннән сорады. Мин, Гайшә, аңарга, бер кыз бар дип, үзебезнең Маһирәне бик мактадым, ничек тә булса бер хәйлә берлә үз кызымызга борасы иде.

Гайшә: Алырга теләсә, бирербезмени соң?

Рәшит: Бирмичә ярамый, анык бәхет инде ул.

Гайшә: Алай булса, аңарга Фәхрине җаучы җибәреп сөйләтергә кирәк, без җибәргәнне әйтмичә яхшылап кына сөйләсен.

Рәшит: Бик яхшы, мин ни эшләргә дә белмичә тора идем әле.

Гайшә дә Фәхри җаучыны җибәрер.

Фәхри барып керер: Хәлим өйдәме?

Хәлим: Өйдә, әйдәгез, рәхим итегез,—дип, бер (көтепханә) кабинетка алып керер.

Фәхри: Сәламәт торасыңмы, Хәлим?

Хәлим: Аллага шөкер әле.

Фәхри: Мине Рәхимә абыстай җибәрде, өйләнергә кели, зинһар барып үзен күр әле, Казанныкы түгелгә күрә, кая сугылырга белми дип әйткәч, синең бик яхшы исемеңне ишеткәнгә, мондый егетне юк-бар кыз берлә әрәм итәргә ярамас дип килдем.

Хәлим: Бик рәхмәт.

Фәхри: Әле соң ул эшең дөресме? Мин тиле кеше төсле үзем әүвәл сөйләп бирдем.

Хәлим: Ул дөрест.

Фәхри: Соң бер-бер кешегә киңәш иткәнең бармы?

Хәлим: Рәшит байга гына сөйләгән идем, бер кызны бик мактады.

Фәхри: Ул кем кызы ди?

Хәлим: Анысын белмим.

Фәхри: Ул Гатаулла бай кызыдыр.

Хәлим: Нинди кыз соң ул, безгә бирерләрме?

Фәхри: Бик яхшы кыз, кызларны яманларга ярамый, бүтән кызларны сөйләмәдеме?

Хәлим: Юк.

Фәхри: Соң бүтән кызлардан кемнәрне исәплисең соң?

Хәлим: Мин һич белмим.

Фәхри: Мин сиңа бер кыз исәпләп торам, атасы-анасы бирсәләр, кызда эш соң калмаган, матурлыккамы дисең, куштанлыккамы дисең, ул укымыш инде, мәнзумә китапларны шатырдатып укый, бирсәләр, яхшы булыр.

Хәлим дә көлемсерәп: Бу кызны син бигрәк мактадың, күңелемне боза яздың.

Фәхри: Дөрест сөйлим, соң сине алдамыйм, Алла сакласын, сәхабә кебек кешене алдап сөйләргә ярыймы соң?

Хәлим: Кем кызы соң ул?

Фәхри: Ул бик яхшы бай кызы, Рәшит байның.

Хәлим: Рәшит байлар бирмәсләр, ул миңа ул турыдан бер дә сүз чыгарганы юк.

Фәхри: Бирмәсәләр, үзләрендә калыр, Аллага тапшырып, сорап карыйк әле. Бирсәләр, ничек булыр?

Хәлим: Белмим, мин бирүләрен бер дә уйламыйм, бик яхшы булыр.

Фәхри: Хуш әле, Хәлим, мин барып карыйм,—дип чыгып китәр.

Китеп, Гайшә абыстай янына барып керер.

Гайшә абыстай: Сәламәт килдеңме?

Фәхри көлеп: Аллага шөкер, мин, Гайшә абыстай, сезгә җаучы булып килдем.

Гайшә: Кемнән?

Фәхри: Хәлимнән.

Маһирә дә, җаучы булып дигәч, Фатихтандыр дип бик шатланса да, Хәлимнән дигәч, башыннан салкын су салган төсле, ишек ачып чыгып китәр.

Гайшә: Ни сөйли?

Фәхри: Сезне, бирмәс дип курка, үзенең аласы бик килә.

Гайшә: Хәзердә Рәшит абзыең өйдә юк, җайлап кына Хәлимгә сөйлә инде. Аллаһ теләсә, бирәмез шул.

Маһирә дә икенче бүлмәдә: Мәрзия, бар әле, тыңлап тор әле, әни ни сөйләр икән.

Мәрзия килеп: Маһирә апа, әниең «ярар, бирермез» дип әйтте, диде.

Маһирә: Ишекне биклә. Уф Алла! Нинди хәйлә берлә котылыйм, сорасалар, ни җавап бирермен. Хәлимне сөймим дип ничек әйтим, ни эшлим соң, Фатихны сөйгәч, Хәлимне ничек сөйим инде. **И** Раббем, бу бәладән ничек котылыйм. Фатихны сөям, Хәлимгә бармыйм дисәм, бөтен кала улап көләр, нишлим соң инде, сөймим шул. Сөймим, ни әйтим? — дип мендәргә ятыр еларга башлар.

Торып, Маһирә: әллә Фатихка хат языйммы, илтәрсеңме, хәзер

кибеттә түгел микән? Улсы да шул хәзер җаучы җибәреп сората башласа иде ичмасам, мин аякка *басар* идем, йөргәнчә генә шул, синнән сөйгән кызы юк, синең төсле кеше күргәне юк, шулай итеп, безнең кызларның күңелләрен бозып кына калдыралар. И Раббем, ник ичмасам Фатих берлә йөрдем инде, үзе хәзер соратмый, үпкәләп хат язган булып, бөтен гомеремне көйдереп уздырыр. Хыянәтле көемчә Хәлим төсле кешегә ничек оялмыйча барыйм. Алай да Фатихка хат язып карыйм әле: «Газизем! Бүген өемезгә Хәлимнән җаучы килде, әтиләр бирмәкче булалар, зинһар, газизем, шул җаучы өстенә җаучы җибәрсәнә, мин аңарга бармыйм дип, сиңа барам дип котылыр идем, югыйсә эшем харап, Хәлимне сөймим дию генә җитми, мине сөйсәң, зинһар тизрәк шул эшләрне эшлә, бик тиз бер хат язып җибәр, ни язарга да белмәдем, елаудан туктаганым юк. Вәссәлам. Маһирә.»

Мәрзия Фатихка илтеп бирер. Фатих каршы хат яза: «Җан дустым! Җәнабе сәгадәтләреңездән фатихалар риҗа идеп сәламнәр юлладым. Язган хатыгыздан бик эчем пошып, бу хатымны күз *яшьләрем берлә яздым* дисәм дә ялган булмас. Мин бу көн җаучы *җибәрә* ал*мыйм,* ничек булса да Хәлимгә бармаска *тырыш, мин* сине алмыйча калмыйм. Әгәр минем сүземне тотмасаң, дөнья-ахирәттә бәхил түгел, минем күңелемне бозып бетереп, икенче кешегә бармакчы буласыңмы әллә? *Вәссәлам*. Фатих.»

Маһирә укып: И Раббем, монда да көенечтән башка нәрсә юк, бу сүзләрне ничек оялмыйча яза икән, ташлап китмәкче буласың дигән булган, бер елдан бирле йөреп алдап бетерде дә, инде җаучы да җибәрми. И Раббем! Ник йөрдем! Каһәр суккан Бәдәр харап итте мине, Бәдәр. Фатихка алданып, Хәлим төсле кешегә бара алмый калсам, Фатих та алмасын. И Раббем, гафифә кыз булсам иде, Хәлимгә барып рәхәтләнеп торыр идем, инде ни эшлим, ни әйтим?!

Мәрзия: Апакай, елама юкка, Хәлимгә хат кына яз,мине алма, файда күрә алмассың, дип.

Маһирә: Аннары Фатих алмаса ни эшләрем?

Мәрзия: Ник алмасын.

Маһирә: Тукта әле, Хәлимгә бер хат языйм: «Шәфкатьле шәкерт! Сез безгә җаучы җибәреп мине соратуыгызга бик рәхмәт, Алла риза булсын. Әниләрнең ни җавап биргәннәрен белмәсәм дә, чамалары бирүдә икәнен беләм, сиңа бирмичә кемгә бирсеннәр, мин дә сине бик яратам, ләкин минем сиңа барырлык эшем юк, бер елдан бирле йөри торган сөяркәм бар, аны ташлап китә алмыйм, икенче, хыянәтле бер кыз булып сезнең шикелле бер кешене әрәм итәсем килми. Бу сүзләремне сине сөймәгәнгә яза дип белмә, сиңа изгелек итеп язам, сиңа барсам да кочагымда син булсаң да, исәбемдә ул булыр. Актыккы сүз — башсызланып алмакчы булсаң, рәхәт күрәм дип уйлама, зинһар безгә шәфкать кылып, мине кире кайтарсана. Аллаһе Тәгалә сезгә үзеңез өчен яратылган гына кыз насыйп өйләсен! Маһирә.»

Хәлим хатны укып, гаҗәпкә калып, кызны кайтарып, Габдерәхим мөгаллим кызын соратып, әүвәл кызына хат язып сорар: «Гафифә кыз! Мин сине соратмакчы булам, атаң-анаң бирсәләр, ризалыгың ничек булыр, минем берлә мәгыйшәтең ничек булыр, кыскача бер мәктүп берлә исәбеңне аңлатмакыңны үтенәм. Хәлим.»

Кыз хатны алып, шатланып хат яза: «Әфәндем! Сезне күрә башлавымнан бирле үземне Хәлимнеке дип тәрбия кылдым, һич гаепсез бер кыз идекемне бер дә курыкмый сөйлим, алсаңыз, бик шатланып кабул итәм, тормышымызны да, Алла теләсә, мөмкин кадәр рәхәт уздырырмыз. Галәйһи вәссәлям.»

Хәлим дә Галиягә җаучы җибәрер, Габдерәхим мөгаллим кабул итеп, Галиягә никях кылырлар, Хәлим дә Галия тугрысында, дөньяда Галиягә башка бер дә хатын юк шикелле, һәрвакыт Галиянең күңелен булдырырга теләр, Галия үзенең Хәлим кебек бер мөгаллимгә (рәфика) иптәш булуына һәрвакыт шатланып, Хәлимнең кадерен белер, бөтен гомерләре берсе-берсе өчен генә яратылган дип, рәхәт-рәхәт гомерләрен уздырырлар.

Тәмам.

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

*Тәгаллем* — белем алу.

*Сәгадәт* — бәхет.

*Әлвидаг* — аерылышу, саубуллашу.

*Ашык* — ашык сөяге белән уйнала торган уен; кузна.

*Тәхсил* — гыйлем алу.

*Голяма* — галимнәр.

*Мәкъсуд* — теләк, омтылыш.

*Әбәди* — мәңгелек.

*Мәсгудият* — бәхетлелек.

*Изен* — рөхсәт, юл кую.

*Шәрик* — иптәш.

*Вазыйфә* — хезмәт хакы.

*Рәһен* — закладка салу.

*Бәни* — мине.

*Тиреслек* — кирелек.

*Җапы* — исеме.

*Дарелтәдрис* — белем бирү йорты.

*Гобудият* — коллык, буйсынучылык.

*Эстәү* — теләү.

*Тәшәккер* — яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.

*Холыйк иделмеш* — яратылган.

*Гарб җәнүби* — Көньяк-көнбатыш.

*Галәме әрзәк* — туендыручы галәм.

*Сада*—аваз, тавыш.

*Тәрмененнән* — моңыннан.

*Тәкәрем* — олылау.

*Гариб* — фәкыйрь.

Кавагыйде гарәби — гарәп теле кагыйдәләре.

Истифтах — керешү, башлау.

Истикмаль — төгәлләү.

Дәрүсе шифаһия — телдән сөйләнгән дәрес.

Гарәби гыйбарәт — гарәпчә язу, җөмлә.

Иҗтиһад — тырышлык.

Игътикад — ышану, инану.

Бәдәл — бәя, хак.

Тәхсил — гыйлем алу.

Тәкәммел — камиллек.

*Шәһадәтнамә* — таныклык язуы, диплом.

*Рисалә* — мәкалә, кечкенә китап.

*Лөгате гарәб* — гарәп теле.

*Лөгате фарси* — фарсы теле.

*Мәһарәт* — осталык, сәләтлелек.

*Истинҗа* — тәһарәттән соң пакълану.

*Дәкыйк* — төгәл.

*Хәким* — бик акыллы һәм белемле кеше.

**Мөяссәр** — җайлау.

*Җәмгъ* — бөтен, барлык, һәммә.

*Кыйраәт* — уку, күрмичә кычкырып уку.

*Саг* — сау.

*Сәнәви* — еллык.

*Аерынлыклы* — аеруча.

*Фөнүн* — фәннәр.

*Фазыл* — өстенлек.

*Ригая* — кайгырту, карау, хөрмәтләү.

*Иҗтиһад* — тырышлык.

*Кавем* — нәсел.

*Тәкмил* — тәмам итү.

*Тәргыйб* — кызыксыну.

*Васыйл* — ирешү, барып җитү.

*Вәсилә* — сәбәп.

*Хәмед* — мактау.

*Каумият* — нәсел, милләт.

*Сәнаигы* нәфисә — матур сәнгать.

*Форсаты* ганимәт — уңышка ирешүдә җайлы чак.

*Мәнзумә* — шагырь белән язылган хикәя.

*Сәхабә* — Мөхәммәт пәйгамбәрнең замандашы булып, аны күргән кеше.

*Җәнабе сәгадәт* — бәхет иясе.

*Риҗа* — үтенү, сорау.

*Гафифә* — гыйффәтле.

**Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер.**

— Г. Исхакыйның басылып чыккан иң беренче хикәясе. Басмасына рөхсәт С.-Петербургта 1899 елның 24 июнендә бирелә. Казанда Чирков хатыны варислары типографиясендә «Мөхәммәтҗан вә борадәре Шәрифҗан әл-Кәрималәрнең матди ярдәме белән» 1899 елда басылып чыга 24 бит. Имза: Гаяз әл-Исхакый.

1897 иче елда ук, 19 яшьлек чагында язган бу хикәясе турында автор үзе боЛай дип яза: «Беренче мәртәбә мин үземнең әсәремне [кешеләргә] кечкенә генә, җылы гына агач өйдә укыдым... Ләкин мин ул вакытта уземнең романым белән, үземнең мөхәррирлегем белән исергәнгә, аракы, әфьюн ашаган кеше кеби түгел, башына, йөрәгенә әллә никадәр яңа исерткеч салынган кеби исергәнгә, әлбәттә, тирә-ягымдагыларны күрми идем.» «...шунысы хәтердә калган, шул үземнең беренче әсәремне ике утыруда язып бетергән идем. Язган вакытта, тиле кеше кеби, вакытны-көнне сизмичә, буйдан-буйга язган идем. Баштагы уй-фикер сыймаганга гына торып, җилләнеп җиңеләер өчен идән буе йөреп-йөреп кенә бүлгәләштергән идем. Төзәтми-нитми шуны күтәреп китапчыга чыккан идем. Аның алдында башны иеп кенә көтеп торганның соңында: «Ярый, басармын», дигән шатлыклы хәбәреме ишеткәннең соңында, гомеремдә беренче мәртәбә әсәремне сатып, шылтыратып акча алып кайткан

идем». Икенче бер урында язучы: «...ул әсәремне бик кыйммәт иттереп саткан идем. Шуның янына тагы бер төрекчә тәрҗемәне кушып, икесенә тулы бөтен өч тәнкәне шылтыратып алып кайткан идем». *(Бер токтарның саташуы. 1914 ел, Казан.)*

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 1 том. - Казан:<br>
Татарстан китап нәшрияты, 1998. Б. 31- 49.<br>
Текстны әзерләүче: Лена Гайнанова